ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирин Батыршин, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Сирин Батыршин урамы, 33йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 2** **29.01.2025 ел**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында»гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

2024 елның 11 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Кәрәкәшле торак пунктының халык җыенының 9 санлы карары;

2024 елның 12 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Ак-Чишмә торак пунктында халык җыенының 11 санлы карары;

2024 елның 12 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Салкын-Чишмә торак пунктында халык җыенының 13 санлы карары;

2024 елның 13 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында халык җыенының 15 санлы карарларын гамәлгә ашыру максатларында,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан бирле үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталында түбәндәге веб адрес буенча хәбәр итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, http://jutaza.tatarstan.ru веб- адресы буенча муниципаль районның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Дәүләтгәрәев

Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2025 елның
29 гыйнварындагы 2 санлы карарына
1 кушымта

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнар, 1 төркем инвалидлар, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның якын туганнары (ата-аналары, хатыннары), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, гражданнар җыенында катнашу-катнашмауларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2025 елның 17 гыйнварыннан 2025 елның 20 мартына кадәр үзара салым акчалары түләүне башкара.

3. Җитди сәбәпләр булган очракта, ә аларга түбәндәгеләр керә ала:

а) торган урын буенча озак яшәмәү,

б) авыру,

гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук имзаны тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын раслый торган касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салымы акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2025 елның
29 гыйнварындагы 2 санлы карарына
2 кушымта

Кәрәкәшле авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
____ санлы
ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А. ___________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________
Халык җыены карары нигезендә торак пунктта______________________Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге 2025 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча сезгә _________ _ _ _ _ кадәр халык җыены чараларын тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләүне түбәндәге реквизитлар буенча башкарырга кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО
Билгеләнгән түләү: 2025 ел өчен Кәрәкәшле авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы.

Җитәкче _____________________________________________________________
П.У. (имза) (имзаны раслау)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Кәрәкәшле авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
№ __________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(муниципаль берәмлек исеме)
_________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А. ___________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________
«__» ________________ 20__ елны __________________________________ алдым
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*